**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ИБРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

№ 1 11.11.2024 ел

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2024 елның 22 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авылы, Совет урамы, 5 йорт адресы буенча Яңа Ибрай авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы вакытта Яңа Ибрай авылы эчендәге юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш китерү, туфрак һәм вак таш салу һәм тигезләү).

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Яңа Ибрай авылында тирәнлек насосын сатып алу һәм алыштыру (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

3.Әлеге карарны Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Кәбиров.

СОВЕТ НОВОИБРАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ